# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

“28” ноябрь 2021 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 27 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2021 елның 27 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта, 2021 елнын 28 ноябрендә 10 сәгать 00 минутта, 2021 елнын 28 ноябрендә 13 сәгать 00 минутта узган этаплы җыеннар нәтиҗәләре белән «Сез 2022 елда Күәм авыл җирлеге Күәм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-төзелеш материаллары сатып алу, Күәм авылы урам юлларын ремонтлау һәм төзекләндерү буенча хезмәтләр өчен түләү.

- Күәм авылы территориясен чистарту (агач һәм куаклар кисү, урамнарны кардан чистарту), эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Күәм авылы зиратлары өчен капкалар сатып алу һәм монтажлау, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыенның беркетмәсе төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 551 (биш йөз илле бер) кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 304 (өч йөз дә дүрт) кеше, бу 55,2 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Риза» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 293 (ике йөз туксан өч) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 11 (унбер) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2022 елда Күәм авыл җирлеге Күәм торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

-төзелеш материаллары сатып алу, Күәм авылы урам юлларын ремонтлау һәм төзекләндерү буенча хезмәтләр өчен түләү.
- Күәм авылы территориясен чистарту (агач һәм куаклар кисү, урамнарны кардан чистарту), эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- Күәм авылы зиратлары өчен капкалар сатып алу һәм монтажлау, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күәм авыл җирлеге Күәм авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күәм авыл җирлеге башлыгы Гатауллин Р.Р.